ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**АКБАШ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ**
БАШЛЫГЫ
423958 Ютазы районы,
Акбаш авылы, Мәктәп урамы, 17
тел. 4-14-34
факс: 8 (85593) 4-14-34

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
**АКБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
423958 Ютазинский район
село Акбаш ул.Школьная, д.17
тел. 4-14-34
факс: 8 (85593) 4-14-34

**Постановление** **Карар**

№ 4 «22» ноябрь 2024 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге составына керүче Акбаш торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Советының 2023 елның 10 ноябрендәге 30 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 26 маддәсенә таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Советының 2019 елның 23 сентябрендәге 15 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында»гы нигезләмәнең 4 бүлегендәге 4.4 бүлекчәсенә нигезләнеп, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Акбаш авылы, Мәктәп урамы, 17 йорт адресы буенча урнашкан Акбаш торак пунктының КФҮ бинасында 2024 елның 05 декабрендә 09 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегенең Акбаш торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләләрне расларга:

2.1. Сез Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегенең Акбаш торак пунктында гражданнар җыенының 2024 елның 15 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге составына керүче Акбаш торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 3 санлы һәм 2024 елның 15 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегенең Акбаш торак пунктында 2025

елда гражданнарга үзара салым кертү турында»гы 4 санлы карарларын үз көчен югалткан дип танырга ризамы?;

2.2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегенең Акбаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә сез ризамы?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Акбаш авыл җирлегенең Акбаш торак пунктында юлларның чокырларын ремонтлау);

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Акбаш торак пунктында юлларны грейдерлау һәм кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу (эшләр һәм хезмәтләр өчен килешү буенча түләү)).

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге башкарма комитетына Акбаш торак пунктында гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә., Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ электрон адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм порталын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ электрон адресы буенча урнаштырырга..

5. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Акбаш авыл җирлеге башлыгы И.Р.Сәхибуллина